**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге составына керүче Керкәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«26» ноябрь 2025 ел № 1

2025 елның 20 мартындагы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль законның 45, 69 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 маддәсе, 2025 елның 26 ноябрендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Керкәле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Керкәле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы тылы хезмәтчәннәреннән, махсус хәрби операциядә катнашучылардан тыш, 2026 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне үтәү буенча хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

- Керкәле торак пунктында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (грейдерлау, юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 23 граждан кертелде;

тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 12 граждан, бу 52% тәшкил итә.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленгән:

«Риза» позициясе өчен 12 граждан тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәрдән чыгып, граданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Керкәле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Керкәле торак пунктында гражданнар җыенының:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Керкәле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы тылы хезмәтчәннәреннән, махсус хәрби операциядә катнашучылардан тыш, 2026 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне үтәү буенча хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

- Керкәле торак пунктында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (грейдерлау, юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү) – соравын кабул ителгән дип санарга.

.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге башлыгы Л.М.Хәйруллина